ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11.2022 с.Старое Дрожжаное №602

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 02 сентябрендәге 459 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**исемендә** «2022 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

**кереш өлешендә** «СанПиН таләпләре 2.4.5.2409-08» сүзләрен «СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләре таләпләре» сүзләренә алмаштырырга;

**1.3 пунктында** «2022 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле **1.3.1 пунктын өстәргә:**

«1.3.1. 2022 елның 1 октябреннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар балалары өчен бушлай кайнар туклануны оештырырга:

- 2022 елга гомуми белем бирү учреждениеләренең расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 1-4 сыйныф укучылары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бер уку көненә укучыларны түләүсез тукландыруны оештыруга каралган субсидияләрдән 55 сум 55 тиен, Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан әлеге категориядәге укучыларны тукландыруны һәм мәктәп яны кишәрлегеннән алынган керемнәрне тукландыруны оештыру өчен 20 сум 00 тиен;

- 2022 елга гомуми белем бирү учреждениеләренең расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 5-11 сыйныф укучылары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бер уку көненә укучыларны түләүсез тукландыруны оештыруга каралган субсидиядән 8 сум 30 тиен, Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан әлеге категориядәге укучыларны тукландыруны һәм мәктәп яны кишәрлегеннән алынган керемнәрне тукландыруны оештыру өчен 20 сум 00 тиен.»;

**4 пунктта** «2022/23 уку елында» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль бюджет учреждениеләре укучыларының өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗларның кайнар туклануын оештыру тәртибе турындагы **нигезләмәдә** (карарга кушымта):

**1 пунктның беренче абзацын** түбәндәге эчтәлекле исемлек белән тулыландырырга:

« - Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын.»;

**2 пунктның 9 абзацында** «СанПиН таләпләрен 2.4.5.2409-08» сүзләрен «СП 2.4.3648-20 санитария кагыйдәләре таләпләрен» сүзләренә алмаштырырга.

2 Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2021 елның 09 декабрендәге 595 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Д.А. Сатдинов